**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең Репьевка торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

29 октябрь, 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең Репьевка торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең Репьевка авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

а) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

б) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Надеждино авыл җирлеге башлыгы Е.В.Савельева